КОНСТИТУЦИОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СОВЕТЫ

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420060
E-Mail: konsovrt@tatar.ru

Пушкина ур., 66/33 йорт, Казан шәһәре, 420060
E-Mail: konsovrt@tatar.ru

10 декабрь, 2025 ел

№ 6

**Гражданин М. К. Фатыйхов мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының конституциячеллеген тикшерү турында**

# НӘТИҖӘ

Татарстан Республикасы Конституция советы, рәисе И.И. Гыйләҗев, әгъзалары Р.Ф. Гафаров, Э.М.Мостафина катнашында, «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә, 11 статьясына таянып, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше 3 пунктының конституциячеллеген тикшерү хакындагы мәсьәләне карады.

Гражданин М.К.Фатыйховның мөрәҗәгате әлеге мәсьәләне карауга сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче күрсәткән норматив-хокукый нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек аны карап тикшерү өчен нигезгә әйләнде.

Татарстан Республикасы Конституция советы, Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы – Э.М. Мостафинаның докладын, утырышта катнашучыларның – гражданин М. К. Фатыйховның, карауга кертелгән Татарстан Республикасы норматив-хокукый актын чыгарган орган вәкиле - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең

конституцион законнар бүлеге мөдире Л.И.Ибраһимова аңлатмаларын, утырышка чакырылганнарның: Татарстан Республикасы Рәисе вәкиле – Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эше бүлеге баш киңәшчесе Е.Е.Шехматова, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы вәкиле – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Р.Г.Миңнегулов, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы вәкиле – Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М. Ибәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкиле – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре буенча бүлек башлыгы урынбасары Э.Ш.Хәбибуллина чыгышлары тыңланып, тапшырылган документлар һәм башка материаллар тикшерелгәннән соң,

БИЛГЕЛӘДЕ:

1. Татарстан Республикасы Конституция советына гражданин М.К. Фатыйховның «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше 3 пунктының (шулай ук алга таба– 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) конституциячеллеген тикшерү турында мөрәҗәгате керде

Мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать итүче үз таләпләрен түбәндәгечә нигезли.

Гражданин М.К. Фатыйхов 1997 елның 24 гыйнварыннан 2005 елның 21 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле җирле үзидарә советы башлыгы вәкаләтләрен башкарган, анда сайланулы вазыйфа буенча ике срок эшләгән. Аннары 2005 елның октябрендә мәктәпкә укытучы булып эшкә кергән.

Гаризада күрсәтелгәнчә, соңрак – 2009 елның 12 февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы № 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын кабул иткән, ә аның 6 статьясы нигезендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү мәсьәләсе җайга салынган.

15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затлар, кайбер шартлар үтәлгәндә, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон) нигезендә билгеләнгән картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә түләү (алга таба – пенсиягә өстәмә түләү) алуга хокуклы. Аерым алганда, әлеге статьяның 1

өлешендәге 3 пунктында пенсиягә өстәмә түләүгә дәгъва кылучы затның 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак муниципаль вазыйфаны биләү зарурилыгы каралган.

Бу уңайдан гражданин М.К. Фатыйхов үз хәленә борчылуын белдерә. Аның ныклы фикеренчә, социаль-финанс хәле үзеннән соң шундый ук вазыйфа биләгән хезмәттәшләренеке белән чагыштырганда сизелерлек начарайган. Мөрәҗәгать итүче, муниципаль хезмәт стажлары азрак булуга һәм күрсәтелгән вазыйфада эшләү вакытлары да кимрәк булуга карамастан, дәгъва белдерелүче норма үз көченә кергәннән соң отставкага киткән хезмәттәшләренең пенсиясенә өстәмә алу хокукына ия булуларын, ә үзенең аңа ия булмавын, гаделсезлек, дип саный. Мөрәҗәгать авторы фикеренчә, бу Татарстан Республикасының Төп Законында билгеләнгән гарантияләргә каршы килү генә түгел, бәлки аны шундый ук шартларда һөнәри эшчәнлек алып баручы башка затлар белән чагыштырганда алдан ук тигез булмаган социаль-икътисадый хәлгә кую да булып тора.

Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгәнчә, гражданин М.К. Фатыйхов эшеннән азат ителгәннән соң аның вазыйфасына башка затлар сайлана. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче, җаваплы һәм үз эшен яхшы белгән кеше буларак, әле озак вакытлар буе җәмәгать башлангычында җирле үзидарә өлкәсендә эшне оештыру мәсьәләләре буенча остаз һәм консультант функцияләрен үтәгән. Шул ук вакытта ул рәсми рәвештә авыл мәктәбенә эшкә урнашкан.

Гражданин М.К. Фатыйхов фикеренчә, парадоксаль хәл килеп чыккан: муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлар өчен каралган социаль гарантияләрне тулы күләмендә алу өчен аңа нибары ике ай эш стажы җитми калган. Ул, 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының кабул ителәчәген белсәм, укытучы вазыйфасына күчүне кичектереп торган булыр идем һәм социаль тәэминатка хокуктан тулысынча файдалану өчен пенсия законнарындагы үзгәрешләрнең үз көченә керүен көтеп торган булыр идем, дип билгеләп үткән.

Мөрәҗәгать итүче, пенсия исәпләүнең мондый тәртибендә гаделсезлек күреп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына аңлатма сорап мөрәҗәгать иткән,әмма аннан пенсиягә өстәмә түләү хокукына ия булмавы турында җавап алган.

Гражданин М.К. Фатыйхов билгеләп үткәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясе, закон алда барысының да тигезлеген игълан итеп, социаль хокукларның тигезлеген һәм һәркемнең социаль тәэминатка хокукын гарантияли, ә бу исә гадел җәмгыятьнең төп принцибы булып тора.

Гражданин М.К. Фатыйхов, бәян ителгәннәр нигезендә, Татарстан Республикасы Конституция советыннан “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын Татарстан Республикасы

Конституциясенең 2, 13, 22, 28 (1 һәм 2 өлешләр), 29 (1 өлеш), 54 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 58 (2 өлеш) статьяларына туры килмәвен тануны сорый, әлеге статьялар нигезендә:

кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң югары кыйммәт булып тора; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы;

Татарстан Республикасы – сәясәте кешенең лаеклы тормышын һәм ирекле үсешен тәэмин итә торган шартлар тудыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт;

Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм тигез бурычлар башкара;

закон һәм суд алдында барысы да тигез; чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашларына, дингә мөнәсәбәтенә, ышануларына, шөгыльләренең төренә һәм характерына, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген гарантияли;

гражданнарның хокукларын социаль, раса, милләт, тел яисә дин билгеләре буенча чикләүнең теләсә нинди рәвешләре тыела;

һәркемгә дә яшь буенча, авырган, инвалид булган, туендыручысын югалткан очракта, балалар тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; дәүләт пенсияләре һәм социаль пособиеләр закон белән билгеләнә;

Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карауга чыгарылган мәсьәлә буенча үз бәяләмәләрен Татарстан Республикасы Конституция советына җибәрде.

Бәяләмәләрдә билгеләп үтелгәнчә, 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезләмәсе федераль законнарда билгеләнгән Россия Федерациясе субъекты компетенциясе чикләрендә кабул ителгән, һәм ул гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын бозу буларак карала алмый,

“Татарстан Республикасы Конституция советы турында” Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Конституция советы бәяләмә чыгарганда, карауга кертелгән норматив-хокукый актның туры мәгънәсен бәяли. Татарстан Республикасы Конституция советы

норматив-хокукый актны караганда шулай ук аңа рәсми аңлатма һәм башка аңлатмалар яисә гамәлдәге хокук куллану практикасы биргән мәгънәне бәяли. Татарстан Республикасы Конституция советы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча гына бәяләмә чыгара, ә норматив-хокукый актны караганда – мөрәҗәгатьтә конституциячеллеге шик астына алынган өлешенә карата гына бәяләмә чыгара. Татарстан Республикасы Конституция советы бәяләмә чыгарганда, мөрәҗәгатьтә бәян ителгән нигезләргә һәм дәлилләргә бәйле була алмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция советының карап тикшерү предметы булып «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты тора, анда муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә айлык өстәмә алу хокукы барлыкка килүе өчен кирәкле шартларның берсе буларак – аның муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак биләве билгеләнгән,

Карауга чыгарылган закон нигезләмәсенә тиешле конституциячел-хокукый бәя Россия Федерациясе Конституция судының хокукый позицияләре контекстында, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларның пенсияләренә өстәмә түләүгә бәйле мәсьәләләрне җайга сала торган федераль законнарның норматив-хокукый актлары белән системалы бәйләнештә бирелергә мөмкин.

2. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларның пенсияләренә өстәмә түләү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелгән нигезләмә социаль тәэмин итү системасының бер өлеше булып торучы пенсия тәэминатын җайга сала торган закон нормаларына карый.

Россия Федерациясе Конституциясе, социаль дәүләт максатлары (7 статья, 1 өлеш) нигезендә, һәркемгә яшь буенча, авыру, инвалидлык, туендыручысын югалту очрагында, балалар тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда (39 статья, 1 өлеш) социаль тәэмин итүне гарантияләп, әлеге конституциячел хокукны гамәлгә ашыру шартларын һәм тәртибен билгели, шул исәптән пенсияләр төрләрен һәм аларга өстәмә түләүләрне билгеләүне, гражданнарның аерым категорияләренең аларга хокук алу нигезләрен билгеләүне закон чыгаручы компетенциясенә кертә (39 статья, 2 өлеш).

Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «ж» пункты) нигезендә, социаль яклау, социаль тәэмин итүне дә кертеп, Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында тора. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясыннан (2 өлеш) күренгәнчә, Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар

нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла.

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс средстволарыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм социаль ярдәм билгеләргә хокуклы (элек әлеге норма «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында»1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3.1 статьясында билгеләнгән иде).

Моннан тыш, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм оешмалар акчалары исәбеннән гражданнарны пенсия белән тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары һәм оешмалар актлары нигезендә җайга салына (1 статьяның 5 пункты).

«Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм муниципаль хезмәткәрләргә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән пенсиягә хокук бирү шартлары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары һәм җирле үзидарә органнары актлары белән билгеләнә..

Әлеге хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 (2 өлеш) һәм 75 (2 пункт) статьяларындагы нигезләмәләргә авазваш, алар нигезендә, дәүләт пенсияләре һәм социаль пособиеләр закон белән билгеләнә; Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр һәм Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә законнар белән җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

Шул рәвешле, шул исәптән муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затны пенсия белән тәэмин итү мәсьәләләрен җайга салучы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә керә.

3. Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә, сәясәте кешенең лаеклы тормышын һәм ирекле үсешен тәэмин итә торган шартлар тудыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт буларак, Россиядә дәүләт пенсияләре, пособиеләр һәм социаль яклауның башка гарантияләре билгеләнә (7 статья); һәркемгә яшь буенча, авыру, инвалидлык, туендыручысын югалту очрагында, балалар тәрбияләү өчен һәм законда каралган башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; дәүләт пенсияләре һәм социаль яклауның башка гарантияләре билгеләнә.шулай ук дәүләт пенсияләре һәм социаль пособиеләр закон белән билгеләнә (39 статья).

Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасын кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң югары кыйммәт булып торган; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау Татарстан Республикасы бурычы булган демократик хокукый һәм социаль дәүләт буларак игълан итә; кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеге гарантияләнә (1 статья, 1 өлеш; 2 һәм 13 статьялар; 28 статья, 2 өлеш).

Социаль тәэминатның мөһим элементы булып пенсия белән тәэмин итү тора. Дәүләт пенсияләре Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы 2 өлеше нигезендә закон белән билгеләнә. Республика закон чыгаручысы, законда пенсиягә хокук алу шартларын, аны исәпләү тәртибен һәм күләмнәрен билгеләп, үз вәкаләтләре чикләрендә, гомуми шартлар белән беррәттән, гражданнарның аерым категорияләренә пенсиягә хокукны гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен дә күздә тотарга хокуклы.

Гражданнарны пенсия белән тәэмин итү, пенсия законнарында каралганча, аларның хезмәт эшчәнлеге характерына, эчтәлегенә һәм шартларына бәйле. Республика закон чыгаручысы, гавами хакимиятне гамәлгә ашыру һәм тиешле органнарның вәкаләтләрен турыдан-туры үтәү эшчәнлегенең аерым шартларын, эчтәлеген һәм характерын исәпкә алып, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга пенсиягә өстәмә түләү билгеләүне күздә тоткан.

Россия Федерациясе субъектларының муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә пенсия белән тәэмин итү мөнәсәбәтләрен җайга салуда катнашуы, Россия Федерациясе Конституция суды үз карарларында күрсәткәнчә, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшләре һәм вәкаләтләре чикләрен конституцион нигездә билгеләү кысаларында, аларның компетенциясе чикләреннән чыкмый (2009 елның 13 октябрендәге 1190-О-О номерлы, 2013 елның 24 гыйнвардагы 63-О номерлы, 2013 елның 23 апрелендәге 656-О номерлы һәм башка билгеләмәләр). Асылда ул муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә пенсия белән тәэмин итү буенча мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда унификация һәм дифференциациянең оптималь ярашуына ирешүгә юнәлдерелгән, һәм Россия Федерациясенең конкрет субъектының социаль-икътисадый үсешен һәм аның үзенчәлекләрен, тиешле территорияләрдә җирле үзидарә мөнәсәбәтләренең

үзенчәлеген дә кертеп, әлеге категориядәге гражданнар өчен пенсия хокукларын гарантияләүнең кирәкле дәрәҗәсен саклау максатларына бәйле (Россия Федерациясе Конституция судының 2015 елның 8 декабрендәге 32-П номерлы карары).

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми хокукый, оештыру һәм икътисадый принциплары, шулай ук дәгъва белдерелә торган норманы кабул итү вакытына аны гамәлгә ашыру гарантияләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (шулай ук алга таба– 131-ФЗ номерлы Федераль закон) белән билгеләнгән иде, ул, аерым нигезләмәләреннән тыш, 2006 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керде.

Әлеге Федераль закон белән җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының (шул исәптән муниципаль берәмлек башлыгының) гавами-хокукый статусы билгеләнгән, аның табигате җирле үзидарә органнары аша халыкның үз хакимиятен гамәлгә ашыруына бәйле, һәм ул әлеге статус бирелгән затка тиешле вазыйфа биләү нигезендә җирле үзидарә эшләре белән идарә итүдә катнашуны тәэмин итә, шуның нәтиҗәсендә затның муниципаль вазыйфага сайлануына бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр, хакимиятне җирле бергәлекнең үзе гамәлгә ашыруына бәйле буларак, үзләренең характеры буенча хезмәт мөнәсәбәтләреннән аерылып тора (Россия Федерациясе Конституция судының 2013 елның 27 июнендәге 15-П номерлы.карары).

Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары статусының әлеге үзенчәлекләре, аерым алганда, муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләренең федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә муниципаль берәмлекләр уставлары белән билгеләнүен күздә тоткан махсус җайга салуның зарурилыгына китерә.

15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү вакытына мондый хокукый җайга салу 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $5^1$ өлешенең беренче абзацында билгеләнгән иде, һәм хәзерге вакытта «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясындагы 2 өлешендә чагылыш тапкан, аның нигезендә, гарантияләре депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә, муниципаль берәмлекләрнең уставлары белән билгеләнә.

Шул рәвешле Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, үзенә бирелгән вәкаләтләре чикләрендә эш итеп, 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында шунда санап үтелгән затлар өчен гарантияләр билгеләгән, шул ук вакытта үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы затларының, 15-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән

шартларны үтәгәндә, картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә түләү хокукын күздә тоткан.

Шулай итеп, 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы күрсәтелгән өлеше нигезендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затлар, түбәндәге шартлар үтәлгәндә, «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә билгеләнгән картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә өстәмә түләү алырга хокуклы:

Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаны, шул исәптән депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфаларын даими нигездә 1995 елның 5 мартыннан 2006 елның 1 гыйнварына кадәр, җирле үзидарә органы вәкаләтләрен кимендә биш ел биләү, йә тулы бер срогын, әмма кимендә өч ел биләү;

вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә вазыйфасыннан азат ителү (шул исәптән вакытыннан алда), гаепле гамәлләренә бәйле рәвештә вәкаләтләре туктатылудан тыш;

муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак биләү;

«Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җитү, яки вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен, яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләү.

Югарыда санап үтелгән барлык шартларны үтәгәндә генә пенсиягә өстәмә түләү хокукы барлыкка килә.

15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 10 өлеше нигезендә билгеләнгәнчә, пенсиягә өстәмә түләүне билгеләү һәм түләү, аның күләмен яңадан исәпләү (индексацияләү), өстәмә түләүне туктатып тору һәм яңарту, 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү өчен күздә тотылган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Үз чиратында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла (43 статья).

Татарстан Республикасы Конституция советы, шуннан чыгып, 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган пенсиягә өстәмәнең, үзенең хокукый эчтәлеге буенча, даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләгән затларга гомуми нигездә билгеләнә торган пенсиядән тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелә торган өстәмә түләү белән тәэмин итү булып торуын билгеләп үтүне кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Конституция суды үзенең карарларында күрсәткәнчә, Россия Федерациясе субъектында дәүләт вазыйфаларын, шулай

ук муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар өчен пенсияләренә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләргә) айлык өстәмә түләүләр, үзләренең хокукый табигате буенча, гомуми нигездә билгеләнә торган пенсиядән тыш, әлеге категориядәге гражданнарны өстәмә түләү белән тәэмин итү булып тора, шуңа күрә закон чыгаручы мондый өстәмә түләүләрне исәпләү кагыйдәләрен һәм аларның күләмен үзгәрткәндә, социаль тәэмин ителешкә хокук.шул исәптән законда билгеләнгән очракларда һәм күләмнәрдә дәүләт пенсиясен алуга конституциячел хокук бозылмый (2009 елның 1 октябрендәге 1060-О-О номерлы, 2017 елның 23 ноябрендәге 2716-О номерлы, 2018 елның 26 ноябрендәге 2910-О номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 584-О номерлы һәм башка билгеләмәләр).

Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга карала торган өстәмә түләү, аларның вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә, федераль законнарда билгеләнмәгән өстәмә гарантия булып тора. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, дәгъва белдерелгән норманы кабул итеп, федераль законнарда бирелгән вәкаләтләр чикләрендә эш иткән, чөнки муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга билгеле бер социаль гарантияләр һәм башка гарантияләр билгеләүче федераль норматив-хокукый актлар кабул итү вакытына аларның күләме, бирү тәртибе һәм шартлары булмаган.

Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы Россия Федерациясе субъектында дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарында вазыйфаларны биләгән затларга тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән бирелә торган тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү яки пенсия рәвешендә өстәмә тәэмин итү тәртибен һәм шартларын кертергә һәм аларны үзгәртергә хокуклы (2007 елның 3 апрелендәге № 332-О-П, 2008 елның 15 гыйнварындагы № 107-О-О һәм № 108-О-О, 2009 елның 1 октябрендәге № 1060-О-О һәм башка билгеләмәләр).

Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларның вәкаләтләрен, шул исәптән аларны өстәмә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру гарантияләрен кертү «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә уздырылган җирле үзидарә реформасына бәйле булганлыктан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге Федераль законның 84 статьясындагы 5 өлеше нигезләмәсен игътибарга алган, аның нигезендә, яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары 2006 елның 1 гыйнварыннан, әлеге Федераль законга туры китереп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга керешкән.

131-ФЗ номерлы Федераль закон гамәлгә кертелгәч, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар, матди һәм социаль

гарантияләргә хокукны, пенсия белән тәэмин итүне, хезмәт пенсиясенә өстәмә түләү хокукын, шул исәптән муниципаль хезмәт белән бәйле кайбер чикләүләрне үтәү бурычын да кертеп, законда каралган барлык хокуклары һәм бурычлары белән тиешле статуска ия булган.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы закон чыгаручысы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты белән муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә алу хокукы барлыкка килүе өчен кирәкле шартларның берсен – муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак биләүне керткән. Мондый хокукый җайга салу, югарыда күрсәтеп үтелгәнчә, республика закон чыгаручысы тарафыннан җирле үзидарәне реформалаштыру кысаларында башкарылган.

Шул рәвешле, карауга чыгарылган 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, әгәр алар әлеге вазыйфаларны 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән датага яисә соңрак биләсә, ягъни яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләрен яңа вазыйфа нигезендә, җирле үзидарә реформасына бәйле рәвештә кабул ителгән яңа хокукый җайга салуга туры китереп, гамәлгә ашыра башлаган датадан биләсә, кагыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, әлеге хокукый күрсәтмәләр белән, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен яңа хезмәт шартларын исәпкә алып, алар өчен социаль гарантияләрнең башка күләмен күздә тоткан, шуның белән дәгъва белдерелә торган закон нормасының гамәлдә булуын вакыт буенча да, затлар даирәсе буенча да билгеләгән.

Бу очракта закон чыгаручы муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән, федераль законнарда һәм 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән статус нигезендә тигез хокукларга ия булган һәм тигез бурычлар башкарган затларның хәлен бер төрле итеп җайга салган, бу Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясына каршы килми.

№ 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезләмәсе 2006 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларның хәлен начарайтмый, чөнки моңа кадәр республика законнарында әлеге категориядәге гражданнар өчен картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә өстәмә түләү алу мөмкинлеге каралмаган булган.

Россия Федерациясе Конституция суды күп тапкырлар күрсәтеп үткәнчә, закон чыгаручы, Россия Федерациясе Конституциясенең 39 (2 өлеш), 72 (1 өлешнең «б», «ж» пунктлары) һәм 76 (2 өлеш) статьялары нигезендә пенсия тәэминатының конкрет төрләрен бирү шартларын һәм тәртибен җайга салып, шул исәптән конституциячел гаделлек һәм тигезлек принципларын

үтәү зарурлыгына бәйле рәвештә. Россия Федерациясе Конституциясенең 19 статьясы (1 өлеш) белән гарантияләнгән тигезлек принцибы универсаль характерга ия, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең барлык өлкәләренә җайга салулы йогынты ясап килә һәм Россия Федерациясе Конституциясендә турыдан-туры билгеләнгән хокукларны һәм ирекләрне генә түгел, ә закон нигезендә бирелә торган хокукларны да законнар белән җайга салуны бәяләүнең конституцион критерие булып тора. Гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан пенсиягә хокук алу һәм пенсия хокукларын гамәлгә ашыру шартларындагы аермалар үзбелдеклеләнеп билгеләнмәскә тиеш – алар объектив төстә акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмияткә ия максатларны күздә тоткан очракта гына рөхсәт ителә, ә бу максатларга ирешү өчен файдаланыла торган хокукый чаралар аларга туры килә (2007 елның 16 июлендәге 12-П номерлы карар).

Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары өчен өстәмә пенсия белән тәэмин итүнең конкрет гарантияләрен билгеләми. Республика закон чыгаручысы күрсәтелгән өлкәдәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу өлкәсендә шактый киң дискрециягә ия, һәм ул, республиканың финанс мөмкинлекләрен һәм башка факторларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләрен үтәп – ә анда хокук өстенлегенең, гаделлекнең, тигезлекнең, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклауның конституциячел принципларын бозмыйча, гавами һәм хосусый мәнфәгатьләр балансын тәэмин итү таләбе күздә тотылган – законда билгеләнгән затлар даирәсенең пенсиягә ай саен өстәмә түләү алу хокукын билгеләргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Конституция советы, югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында билгеләнгән хокукый җайга салу – ә ул муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә алу хокукы барлыкка килүе өчен кирәкле шартларның берсен – тәгаенләп әйткәндә, аның 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак муниципаль вазыйфаны биләвен күздә тота – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан аның дискрецион вәкаләтләре чикләрендә, социаль-икътисадый үсешнең шушы этабында республиканың финанс чараларын һәм башка чараларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, кабул ителгән, дигән нәтиҗәгә килде.Карауга чыгарлыган торган җайга салу муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларны өстәмә матди тәэмин итүнең хокукый табигатенә туры килә һәм акылга ярашлылык, нигезлелек критерийларына җавап бирә, чөнки нәкъ менә 2006 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның яңа системасын гамәлгә керткән һәм муниципаль вазыйфаларны биләгән затларның гавами-

хокукый статусын комплексны билгеләгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре үз көченә кергән.

Шул рәвешле, әлеге нигезләмә үзенең эчтәлеге һәм конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый, димәк, ул Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 22, 28 (1 һәм 2 өлешләр), 29 (1 өлеш), 54 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 58 (2 өлеш) статьяларына туры килә.

Татарстан Республикасы Конституция советы, югарыда бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлеше, 11 статьясы, Татарстан Республикасы Конституция советы Регламентының 32-35 статьялары нигезендә,

НӘТИҖӘ ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын – ә анда муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә айлык өстәмә алу хокукы барлыкка килүе өчен кирәкле шартларның берсе буларак, аның муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) соңрак биләве күздә тотылган – Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 22, 28 (1 һәм 2 өлешләр), 29 (1 өлеш) статьяларына туры килүен танырга.

2. Әлеге Нәтиҗәне «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»на (PRAVO.TATARSTAN.RU), Татарстан Республикасы Конституция советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга,

Татарстан Республикасы
Конституция советы рәисе — И.И. Гыйләҗев

Татарстан Республикасы
Конституция советы
әгъзалары — Р.Ф. Гафаров
Э.М. Мостафина